КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 ноябрь г.Казань № 1052

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1059 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1059 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, тормышта авыр хәлдә калган балаларны карап тоту һәм тәрбияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты»;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, тормышта авыр хәлдә калган балаларны карап тоту һәм тәрбияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын расларга.»;

әлеге карар белән расланган Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, тормышта авыр хәлдә калган балаларны карап тоту һәм тәрбияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты»;

1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучылар

Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, тормышта авыр хәлдә калган балалар өчен балалар йортларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәтеннән (алга таба – дәүләт хезмәте) файдаланучылар булып ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, тормышта авыр хәлдә калган балалар (алга таба – балалар) тора.»;

6.2 нче пунктта «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга;

8.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. Педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукы урта һөнәри яки югары белеме булган һәм квалификация белешмәлекләрендә һәм (яки) һөнәри стандартларда күрсәтелгән квалификация таләпләренә җавап биргән затларда була.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә балалар йортындагы педагогик эшчәнлеккә түбәндәге затлар кертелми:

законлы көченә кергән суд карары нигезендә педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителгән;

шәхеснең гомере һәм сәламәтлегенә, иреге, намусы һәм горурлыгына каршы (стационар шартларында психиатрия ярдәме күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз госпитальләштерүдән һәм яла ягудан тыш), шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, конституцион төзелеш нигезләренә һәм дәүләт иминлегенә, кешелек тынычлыгы һәм куркынычсызлыгына каршы, шулай ук җәмәгатьчелек куркынычсызлыгына каршы кылган җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләвенә дучар булган (аклау сәбәпле аларга карата җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), хөкемгә тартылган яки тартылган булган (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән һәм бу пунктның сигезенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш);

башка аңлы рәвештә эшләнгән авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен суд хөкеме гамәлдән чыгарылмаган яки тәмамланмаган булган;

федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә хокукка сәләтсез дип танылган;

сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы раслый торган исемлектә каралган авырулары булган.

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы 2 өлешенең өченче абзацы нигезендә бу пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән затлар арасыннан шәхеснең гомере һәм сәламәтлегенә, иреге, намусы һәм горурлыгына каршы (стационар шартларында психиатрия ярдәме күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз госпитальләштерүдән һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга каршы, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, конституцион төзелеш нигезләренә һәм дәүләт иминлегенә, кешелек тынычлыгы һәм куркынычсызлыгына каршы, шулай ук җәмәгатьчелек куркынычсызлыгына

каршы зур булмаган авырлыктагы җинаятьләр кылган һәм уртача авырлыктагы җигаятьләр кылган өчен хөкемгә тартылган булган затлар һәм акланмый торган нигезләр буенча җинаятьләр кылуда гаепләү туктатылган затлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан оештырылган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең аларга педагогик эшчәнлеккә белән шөгыльләнергә рөхсәт бирү турындагы карары булган очракта, педагогик эшчәнлеккә кертелә.

12 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәмәүгә карата шикаять бирү, аны теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен бозуга карата, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын үтәмәүгә шикаять (алга таба – шикаять) белем бирү оешмасына язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада балалар йортына бирелә. Балалар йорты җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бирелә.

12.2. Балалар йорты, балалар йорты җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, балалар йортының рәсми сайтын, Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталын, бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталын файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Балалар йортына яки Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына кергән шикаять – аны теркәгән көннән 15 эш көне эчендә, ә балалар йорты тарафыннан гариза бирүченең документларын кабул итүдән йә җибәрелгән хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата шикаять биргән очракта яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять биргән очракта, аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

12.5. Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнар нигезендә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча һәм, аны кабул иткән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

12.6. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә бирелә торган җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында балалар йорты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану максатларында гариза бирүче тарафыннан кылынырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелә алмый дип танылган очракта, гариза

бирүчегә бирелә торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин